«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының
Олы Бортас авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы
КАРАРЫ

**2024 елның 25 октябре** **№ 98**

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Бортас авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2023 елның 21 ноябрендәге 78 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында.

Россия Федерациясе Салым кодексының 387 статьясындагы 2 пункты, шулай ук «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Бортас авыл җирлеге " муниципаль берәмлеге Уставының 38 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Бортас авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

2 пунктның 2.4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4. Гомуми мәйданы 1000 квадрат метрдан артыграк булган сәүдә һәм административ-эшлекле үзәкләргә (комплексларга) һәм алардагы Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән урыннарга һәм 10 пунктның икенче абзацында каралган салым салу объектларына карата 2025-2027 еллар күчеш чорына 1,2 процент Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 маддәләре;

һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән салым салу объектларына карата 2 процент ;».

2. Әлеге карарның 1.1 пунктының икенче абзацы 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Олы Бортас авыл җирлеге башлыгы,
Кама Тамагы муниципаль районы
Олы Бортас авыл җирлеге Советы рәисе Р. С. Сагдиев